**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӨҖЕМ АВЫЛ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422008, Таш-Чишмә авылы,
Ш.Усманов урамы, 1Б
Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

**УЗЮМСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422008, село Таш-Чишма, ул.
Ш.Усманова, д.1Б
Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

---

# КАРАР

«03» апреля 2023 г. № 6

**Өҗем авыл башкарма комитетының 2017 елның 28 февралендә, 4 нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә” үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 декабрендәге № 2151 нче номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалткан дип тану турында”гы карарына нигезләнеп, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.

1.1.10 нчы пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:
“Сатып алулар гамәлгә ашырылган очракта Федераль законның 82 статьясы нигезендә план-графикка үзгәрешләр кертү сатып алуларда катнашучыларга котировкалар бирү турында запрос җибәрелгән көннән дә соңга калмыйча, ә сатып алулар башкарылган очракта Федераль законның 93 статьясының 1 өлешендәге 9 пункты нигезендә бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) контракт төзелгән көннән дә соңга калмыйча башкарыла.”

1.2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30.09.2019 ел, № 1279 номерлы «Сатып алу планнары-графикларын формалаштыру, раслау, мондый планнарга-графикларга үзгәрешләр кертү, сатып алу өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алу планнары-графикларын урнаштыру тәртибен билгеләү, мондый планнарга-графикларга мәгълүмат кертү үзенчәлекләрен һәм сатып алу планнары-графиклары формасына таләпләрне билгеләү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын танып” карары нигезендә 12 нче пункт үз көчен югалта.

1.3. 14 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:
“План-график Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 сентябрендәге 1279 номерлы «Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау, мондый планнарга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алуларның план-графигын урнаштыру, мәгълүматны сатып алуларның план-графикларына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» гы таләпләренә туры китереп төзелә.”

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.